Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Совет Ижевского сельского поселения
423647, с. Ижевка, ул. Советская, д. 25
ИНН 1627001020, КПП 162701001
ОКПО 02790667

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл жерлеге советы
423647, Ижевка авылы Совет урамы, 25
ИНН 1627001020, КПП 162701001
ОКПО 02790667

Тел. (факс): (85549) 3-67-89 e-mail: igev.Men@tatar.ru

**12.10.2023** ел **№ 107**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлегендә
бюджет процессы турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 мартындагы 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 41 статьясындагы 11 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. Нигезләмәнең 61 статьясында 2 пунктының 6 абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. Нигезләмәнең 21 статьясында 12 пунктының 3 абзацына түбәндәге редакциядә 4 һәм 5 пунктчалар өстәргә:

«4) хисап финанс елында файдаланылмаган товарларны җитештерүгә (реализацияләүгә) , эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелгән субсидияләрнең калган өлешләрен алучы агымдагы финанс елында субсидияләр (субсидия алучыларның күрсәтелгән субсидияләр финанс тәэминаты чыганагы булган акчаларын түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш) алган очраклар һәм аларны кире кайтару тәртибе;

5) субсидияләр алучыларга һәм әлеге статьяның 5 пунктында күрсәтелгән затларга карата субсидияләр бирүче бюджет акчаларының Баш идарәчесе (идарәчесе) тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәүләрен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә тикшерүләрне гамәлгә ашыру турында нигезләмәләр .»

2. Әлеге карарны Ижевка авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleeevsk.tatar.ru "Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге Советы рәисе урынбасары Р.М. Вәлеев